**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы**
**Бессоново авыл җирлегенең Бессоново торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**09 декабрь 2019 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоново авыл җирлегенең Бессоново торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Бессоново авыл җирлегенең Бессоново торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, күпбалалы гаиләләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүне гамәлгә ашырырга.

2. Аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Бессоново авылы эчендәге юлларны төзекләндерү;
- Бессоново авылында Стаханов урамы буенча буаны төзекләндерү;
- Бессоново авылы зираты территориясенең койма белән әйләндереп алынган җиренә яктырткычлар һәм энергияне саклаучы урамнарны яктырту лампалары сатып алу һәм урнаштыру.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **И.З. Сахауов**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Бессоново авыл җирлеге башлыгы**
**урынбасары** **В.М. Журавлев**